| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.02.2019 № 156

«Индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларын билгеләнгән параметрларга һәм рөхсәт ителгән (рөхсәт ителмәгән) җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын урнаштыруның рөхсәт ителгән параметрларына туры килү (туры килмәү) турында»гы хәбәрнамә юнәлеше буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының "Муниципаль учреждениеләр һәм Алабуга муниципаль районның җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында”гы 2012 елның 27 февралендәге 149 нчы санлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларын билгеләнгән параметрларга һәм рөхсәт ителгән (рөхсәт ителмәгән) җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын урнаштыруның рөхсәт ителгән параметрларына туры килү (туры килмәү) турында»гы хәбәрнамә юнәлеше буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары З.Ә. Касыймовка йөкләргә.

Җитәкче Р. С. Хәйруллин